**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

29 апрель 2019 ел Калмаш авылы № 8

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар акчалары хисабына гамәлгә ашырыла торган чыгымнар юнәлешен раслау турында

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатында һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2019 елның 12 апрелендәге 1364 санлы «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсе 3 пункты һәм«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 15 маддәсе 2 өлеше нигезендә авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетыннан алына торган башка бюджетара трансфертлар акчалары хисабына гамәлгә ашырыла торган чыгымнар юнәлешен расларга.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үзҗаваплылыгымда калдырам.

Калмаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе Р.К.Габдуллина